| СОВЕТ ДРОЖЖАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧҮПРӘЛЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ |
|---|---|---|

**РЕШЕНИЕ** с.Старое Дрожжаное **КАРАР**

2019 елның 17 декабре № 40/2

2020 елга һәм 2021, 2022 еллар план чорына
Татарстан Республикасы Чүпрәле
муниципаль районының бюджеты турында

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставының 29 һәм 92 статьялары нигезендә, Чүпрәле муниципаль районында бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәгә таянып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

**«1 статья**

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы бюджетының төп характеристикаларын раслау турында:

1) Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы бюджетының фаразланган гомуми керем күләме 633553,5 мең сум күләмендә;

2) Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 633553,5 мең сум;

3) Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы бюджеты кытлыгы нульгә тигез.

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының 2021 елга һәм 2022 елга бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) 2021 елга Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы бюджетының фаразланган гомуми кереме 640723,22 мең сум күләмендә һәм 2022 елга 647908,24 мең сум күләмендә;

2) Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы бюджетының 2021 елга гомуми чыгымнары күләме 640490,62 мең сум күләмендә, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 11164,92 мең сум, һәм 2022 елга 647908,24 мең сум күләмендә, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 22657,64 мең сум күләмендә;

3) 2021 елга һәм 2022 елга Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы бюджетының дефициты нульгә тигез.

3. 2020 елга һәм 2021, 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә билгеләргә.

**2 статья**

1. 2021 елның 1 гыйнварына Чүпрәле муниципаль районының муниципаль эчке бурычының иң югары чиген 0 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән Чүпрәле муниципаль районының муниципаль гарантияләре буенча муниципаль эчке бурычының иң югары чиген Россия Федерациясе валютасында нульле күрсәткеч белән расларга.

2. 2022 елның 1 гыйнварына Чүпрәле муниципаль районының муниципаль эчке бурычының иң югары чиген 0 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән Чүпрәле муниципаль районының муниципаль гарантияләре буенча муниципаль эчке бурычының иң югары чиген Россия Федерациясе валютасында нульле күрсәткеч белән расларга.

3. 2023 елның 1 гыйнварына Чүпрәле муниципаль районының муниципаль эчке бурычының иң югары чиген 0 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән Чүпрәле муниципаль районының муниципаль гарантияләре буенча муниципаль эчке бурычының иң югары чиген Россия Федерациясе валютасында нульле күрсәткеч белән расларга.

**3 статья**

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы бюджетында 2020 елга һәм 2021, 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы бюджетының фаразланган керемнәрнең күләмен әлеге карарның 2 нче кушымтасы нигезендә исәпкә алырга.

**4 статья**

2020 елга һәм 2021, 2022 еллар план чорына Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары арасында керемнәрне бүлү нормативларын әлеге карарның 3 нче кушымтасы нигезендә расларга.

**5 статья**

2020-2022 елларда Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы муниципаль унитар предприятиеләре табышының 2019 ел йомгаклары буенча салымнар һәм башка мәҗбүри түләүләр түләгәннән соң кала торган өлешен Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы бюджетына күчерү 2020 елның 1 июленә кадәр чиста табышның 30 проценты күләмендә башкарыла дип билгеләргә.

**6 статья**

1. «Чүпрәле муниципаль районы бюджеты керемнәренең Баш администраторлары – Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары исемлеге» һәм «Чүпрәле муниципаль районы бюджеты

**10 статья**

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы бюджетында 2020 елда республика бюджетыннан алынган бюджетара трансфертларны әлеге карарның 11 нче кушымтасы нигезендә 486086, мең сум күләмендә, 2021 елда 490480,82 мең сум күләмендә, 2022 елда 494908,34 мең сум күләмендә исәпкә алырга.

**11 статья**

Чүпрәле муниципаль районы Юл фондының бюджет ассигнованиеләре күләмен 2020 елга 13700 мең сум, 2021 елга 15200 мең сум, 2022 елга 16000 мең сум күләмендә расларга һәм аларны Чүпрәле муниципаль районының гомуми файдаланудагы юлларында 2020-2022 елларга юл эшләре программасы чараларын тормышка ашыруга юнәлдерергә.

**12 статья**

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының җирле үзидарә органнары 2020-2022 елларда бюджет өлкәсенең муниципаль хезмәткәрләре һәм учреждениеләре һәм башка оешмалары хезмәткәрләре санын арттыруга китерә торган карарлар, шулай ук аларны тотуга чыгымнар кабул итәргә хокуклы түгел.

2. Җирле үзидарә органнарына 2020-2022 елларда муниципаль хезмәткәрләр һәм бюджет өлкәсе учреждениеләре һәм башка оешмалар хезмәткәрләре санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итмәскә тәкъдим итәргә.

**13 статья**

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы бюджетын үтәгәндә әлеге карар белән расланган керемнәрнең гомуми күләменнән фактта алынган керемнәр, әлеге карарга үзгәрешләр кертмичә, муниципаль бурычларны түләүгә, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет Кодексының 217 статьясындагы 3 пунктында каралган күләмдә бюджет ассигнованиеләре җитмәгән очракта, гавами норматив йөкләмәләрне үтәүгә билгеләнгән тәртиптә җибәрелә.

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы бюджетын үтәгәндә әлеге карар белән расланган керемнәрдән артык фактта алынган субсидияләр һәм субвенцияләр, әлеге карарга үзгәрешләр кертмичә генә, җыелма бюджет язмасына үзгәрешләр кертмичә, субсидияләр һәм субвенцияләр бирү максатларына чыгымнарны арттыруга җибәрелә.

3. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы әлеге карарның 1 пунктында каралган максатларга чыгымнарны гамәлгә ашырганнан соң 2020-2022 елларда өстәмә керемнәр җибәрергә хокуклы:

1) хезмәт хакын арттыру чараларын тормышка ашыру;

2) капиталь кертемнәр;

3) учреждениеләрне тотуга агымдагы чыгымнар;

4) торак-коммуналь хуҗалыгын модернизацияләү, торак пунктларны төзекләндерүгә;

5) юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш), шәхси эшмәкәрләргә, физик затларга – товар, эш, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә субсидияләр;

6) иҗтимагый һәм коммерциягә карамаган башка оешмаларга чыгымнарны өлешчә каплау өчен субсидияләр;

7) муниципаль преференцияләр бирү;

8) башка чыгымнар.

**14 статья**

2020 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы исеменнән төзелгән, 2019 елда әлеге муниципаль контрактлар шартлары нигезендә түләнергә тиешле товарлар белән тәэмин итүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә контрактлар суммасыннан файдаланылмаган бюджет ассигнованиеләренең калдыгы суммасыннан артмаган күләмдә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы бюджеты акчалары 2020 елда әлеге максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыруга җибәрелә дип билгеләргә.

**15 статья**

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнары Татарстан республикасы бюджетын үтәүне, шулай ук төзелгән килешүләр нигезендә муниципаль берәмлекләр бюджетларын үтәү буенча аерым функцияләрне гамәлгә ашыра.

**16 статья**

Әлеге Карар 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

**17 статья**

Әлеге Карарны «Туган як»газетасында бастырырга.».

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль
районы башлыгы, Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы Советы Рәисе: М.Р. Гафаров